Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР №XXX-4**

Балык Бистәсе штп. 2018 елның 12 апреле

Россия Федерациясе халыклары мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрнең) бердәм дәүләт реестрына кертелгән файдаланылмаучы торышы ягыннан канәгатьләнмәслек хәлдәге Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы милке булып саналган мәдәни мирас объектлары өчен ташламалы аренда түләвен гамәлгә кертү Тәртибен раслау турында

2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы “Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләре) турында”гы Федераль законның 14.1маддәсе 7 пункты, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. Россия Федерациясе халыклары мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрнең) бердәм дәүләт реестрына кертелгән файдаланылмаучы торышы ягыннан канәгатьләнмәслек хәлдәге Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы милке булып саналган мәдәни мирас объектлары өчен ташламалы аренда түләвен гамәлгә кертү Тәртибен расларга (Тәртип теркәлә).

2.Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча мәгълүмати-телекоммуникацион Интернет челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча мәгълүмати-телекоммуникацион Интернет челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре Палатасына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советы рәисе
урынбасары И.Г.Ибраһимов

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советының
2018 елның 12 апрелендәге
XXX-4 номерлы карары белән
расланды

**Россия Федерациясе халыклары мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрнең) бердәм дәүләт реестрына кертелгән файдаланылмаучы торышы ягыннан канәгатьләнмәслек хәлдәге ТатарстанРеспубликасы Балык Бистәсе муниципаль районы милке булып саналган мәдәни мирас объектлары өчен ташламалы аренда түләвен гамәлгә кертү**
**Тәртибе**

1.Тәртип Россия Федерациясе халыклары мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрнең) бердәм дәүләт реестрына кертелгән файдаланылмаучы торышы ягыннан канәгатьләнмәслек хәлдәге Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы милке булып саналган мәдәни мирас объектлары өчен ташламалы аренда түләвен гамәлгә кертү кагыйдәләрен билгели (алга таба – мәдәни мирас объектлары).

2.Ташламалы аренда түләвен гамәлгә кертү шартлары булып:

- мәдәни мирас объектының торышы ягыннан канәгатьләнмәслек хәлдәге объект булуы, Россия Федерациясе халыклары мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрнең) бердәм дәүләт реестрына кертелгән торышы ягыннан канәгатьләнмәслек хәлдә булган мәдәни мирас объектлары исемлегенә кертелүе, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2015 елның 29 июнендәге 646 номерлы,“Россия Федерациясе халыклары мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрнең) бердәм дәүләт реестрына кертелгән торышы ягыннан канәгатьләнмәслек хәлдә булган мәдәни мирас объектлары исемлегенә кертү критерийларын раслау турында”гы карары белән расланган критерийларга туры килүе;

-арендаторның 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы “Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләре) турында”гы Федераль законда каралган саклау бурычына туры китереп күрсәтелгән мәдәни мирас объектының Россия е законнары нигезендә арендага тапшырылу көненнән 7 елдан артмаган срокта (мәдәни мирас объектын саклау буенча проект документациясен арендага тапшырылганнан 2 елдан да соңармыйча хәзерләү һәм килештерү срогын да кертеп) мәдәни мирас объектын саклау буенча эш алып бару йөкләмәсе тора.

3. Мәдәни мирас объектларына карата ташламалы аренда түләве аренда килешүе төзү хокукына аукцион үткәрү (алга таба – аукцион) нәтиҗәләре буенча билгеләнә.

4. Аукционны үткәргәндә аренда түләвенең башлангыч күләме мәдәни мирас объекты мәйданының 1 кв. метры өчен елга 1 сум күләмендә билгеләнә.

5.Аукцион үткәрү нәтиҗәләре буенча билгеләнгән аренда түләве күләме аренда килешүе гамәлдә булган чорда артмый.